ТАТАРЧА ҖАВАП
Татарстан халкы хакимият органнарына нинди телдә сорау юллый?
> 2

КАЙДА СИН, ДУС?
Балалар әдәбиятына заманча геройлар җитми
> 3

ЧИКНЕ УЗУ
Һәр елны 1 апрельдә күз алдыма шушы күренеш килеп баса...
> 4

МАРАТ КӘБИРОВ:
«Дөньядагы кешеләрнең туксан проценты уйлау-анализлау сәләтеннән мәхрүм»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 46 (29013) | Шимбә | 1 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ӘТИЛӘРГӘ ЯЛ КИРӘК

65 яшь тулганны көтәсе юк. Россиядә ир-атларны пенсиягә вакытыннан алдарак җибәрә башларга тәкъдим иткәннәр. Дөрес, барысын да түгел. Яңалык күпбалалы әтиләргә кагыла. Хәер, моннан әниләр дә, бәбиләр дә отачак, диләр. Ишле гаилә башлыкларына ярдәм кирәкме? Бу хакта ир-атларның үзләреннән сораштык.

Берәүләр гаилә корырга ашыкмыйча, чалбар туздырып йөргән арада өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче ир-атларны пенсиягә вакытыннан алдарак җибәрү турындагы тәкъдим моңа кадәр дә яңгыраган иде инде. Пенсия реформасының тәэсирен бераз булса да җиңеләйтү максатыннан, 2020 елда күрше Удмуртия Дәүләт Советы депутатлары, күпбалалы әниләргә генә түгел, ә күпбалалы әтиләргә дә лаеклы ялга чыкканда ташлама ясарга кирәк, дип белдерде. Моның өчен якынча 5 миллиард сум акча кирәк булачак икәнен дә әйттеләр. Тик ул вакытта закон проекты югарыда кызыксыну уятмады булса кирәк, аны кире кактылар. Боз урыныннан кузгалган әнә. Россия Дәүләт Думасының әле быелның гыйнварында гына оешкан Традицион гаилә кыйммәтләрен ныгыту буенча эшче төркеме күпбалалы әтиләрне пенсиягә иртәрәк җибәрә башлауны якын арада ук хәл итмәкче. Тиешле закон проектын әзерләгәннәр дә инде. Аны чираттагы сессия утырышында ук карап тикшерәчәкләр дип көтелә.

Билгеле булганча, илдә пенсия яшен акрынлап арттыруга корылган реформа 2028 елга кадәр дәвам итәчәк. 2028 елдан хатын-кызлар – 60, ә ир-атлар 65 яшьтән пенсиягә чыгачак. Күпбалалы әниләргә исә азрак эшлисе. Өч бала үстерүче хатын-кызлар – 57, дүрт бала тәрбияләүчеләр – 56, ә биш бала әниләре 50 яшьтән лаеклы ялга китә ала. Алга таба күпбалалы әтиләргә дә пенсиягә иртәрәк чыгу хокукын бирмәкчеләр.

ХАТЫН-КЫЗЛАР ҺӘМ ИР-АТЛАР ӨЧЕН КАРТЛЫК БУЕНЧА ПЕНСИЯГӘ ЧЫГУ ЯШЕ



– Яңалыкны ике куллап хуплыйбыз, – ди «Татарстанның күпбалалы әтиләре» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Артем Кузнецов. – Еш кына әти кеше ишле гаиләнең бердәнбер туендыручысы булып тора. Аңлашыла ки, әниләр бала тәрбияләү белән шөгыльләнә. Шуңа күрә әтиләр ике, өч, биш кеше өчен эшли. Өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче ир-атларны иртәрәк пенсиягә җибәрү – гадел, нигезләнгән һәм бик тә кирәкле адым.

Яңалык якынча 1,5 миллион әтигә кагылачак. Пенсионерлар «армия»сенә тагын бу кадәр кеше килеп өстәлү ил бюджетын какшатырга мөмкин, дигән фикер белдергән Югары икътисад мәктәбенең Вазгыяти тикшеренүләр үзәге директоры Георгий Остапкович. «Ир-атлар өч елга иртәрәк пенсиягә чыгачак икән, димәк, алар товар җитештерүдән туктап, аны куллануга күчәчәк. Ил казнасы моңа чыдармы, белмим. Без бүген болай да бюджет дефициты шартларында яшибез. Күп нәрсәләр икътисадый вазгыятькә бәйле», – дигән ул.

Татарстанның Әтиләр берлеге рәисе Гадел Заһретдинов әйтүенчә, күпбалалы әтиләрне пенсиягә иртәрәк җибәрү ишле гаиләләргә ярдәм чарасы булып тора.

– Моны ир-атларның бала тәрбияләүдәге ролен тану дип кабул итәм. Әлеге адым әтиләрнең социаль статусын күтәрергә дә ярдәм итәчәк. Ничек кенә булмасын, киң җәмәгатьчелек фикере һәм дәүләтнең икътисадый мөмкинлекләреннән чыгып эш итәргә кирәк. Күпбалалы әтиләрне пенсиягә иртәрәк җибәрү, чыннан да, пенсия системасына тәэсир итәргә мөмкин. Шуңа күрә моның бөтен уңай һәм тискәре якларын исәпкә алу зарур. Мәсьәләнең тагын бер ягы да бар: илдә ир-атларның уртача гомер озынлыгы шул пенсиягә чыгу яшеннән әллә ни артмый. Лаеклы ялга чыгу яшенә җитмәүчеләр дә күп. Ә күпбалалы әтиләрне пенсиягә иртәрәк җибәрсәләр, бәлки, алар якыннары һәм туганнары янында күбрәк вакыт уздыра алыр. Бу – яхшы тәкъдим, әлбәттә. Әмма илдә туучылар санын арттыру өчен ишле гаиләләргә субсидияләр, торак белән тәэмин итү кебек ярдәм чаралары мөһимрәк, – ди Гадел Заһретдинов.

Гаилә архивыннан

«Бер бала – юк бала, ике бала – бер бала», – ди халык. Бүген дүрт-биш бала тәрбияләүче гаиләләр дә күп. Ишле гаиләләргә ярдәмнең кайсы да артык түгел», – ди өч ир бала әтисе, җырчы Илназ Баһ.

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов сүзләренә караганда, иң элек «күпбалалы әти» атамасына ачыклык кертергә кирәк. Өч һәм аннан да күбрәк бала әтисенең ул-кызлары бер гаиләдә үсмәскә дә мөмкин бит. Мондый ир-атлар ярдәмгә лаеклымы? Шуны ачыклап бетерсеннәр.

– Бу гамәл ир-атларның статусын да, җаваплылыгын да арттырачак дип уйлыйм. Бәлки, аерылышучылар саны да кимер әле. Бүген үз арабызда да гаиләсен таркатучылар шактый. Сәбәпләре төрледер, билгеле. Әмма яңа закон бу мәсьәләдә уңай йогынты ясарга мөмкин. Ә икътисад күзлегеннән караганда, Россия Социаль фондында акча җитәрлек булмаса, мондый адымга бармаслар иде. Илнең күпбалалы әтиләрне пенсия белән тәэмин итү өчен бөтен мөмкинлекләре дә бар, дип саныйм. Пенсиягә чыгу эштән туктау дигән сүз түгел бит әле. Бүген хәрбиләр, укытучылар кебек лаеклы ялга чыкканда ташламага ия булучылар пенсия билгеләнгәч тә эшләвен дәвам иттерә. Хезмәт хакы алмасаң, бер пенсия акчасына гына иркенләп яшәп булмый, – ди Илгизәр Гайнетдинов.

Сак бул!

17 апрельдән Татарстанда янгынга каршы махсус режим кертелә. Ул 10 майга кадәр гамәлдә булачак. Министрлар Кабинеты карары нигезендә, бу чорда учак ягарга, көнкүреш калдыклары, чүп-чар, чыбык-чабык яндырырга ярамый. Шулай ук урманга якын урнашкан авылбистәләрдә, шәһәр яны бакчалары, балалар лагерьларында, ачык утка куеп, мангалларда, башка махсус савытларда ризык әзерләү тыела.

Бу чорда министрлыклар һәм ведомстволар үз карамагындагы объектларның тирә-юнен чүп-чардан чистарту, янгын куркынычын күздә тотып, су белән тәэмин итү чыганакларының төзеклеген тикшерү, ут чыгу куркынычы янаган эшләрне чикләү буенча чаралар күрергә тиеш.

Сүз уңаеннан, бу атнада республикада урманнар һәм торак пунктларны янгыннан саклау эшен оештыру чаралары расланган.

Икенче дулкын көтелми

Россия Хәрби көчләренең Генераль штабы мобилизациянең икенче дулкыны булу-булмауга ачыклык кертте. Генераль штабның оештыру-мобилизация баш идарәсе җитәкчесе, контр-адмирал Владимир Цимлянский белдерүенчә, кабат мобилизация игълан итүнең кирәге юк – үз теләге белән киткән һәм чакырылган хәрбиләрнең саны җитәрлек. Бу хакта ТАСС хәбәр итә.

«Генераль штаб мобилизациянең икенче дулкынын уздырырга җыенмый: моны мин ышандырып әйтә алам. Хәрби хезмәткә чакырылган, шулай ук махсус операциядә катнашырга теләк белдергән кешеләрнең саны хәрби бурычларны үтәү өчен җитәрлек», – дигән ул.

Владимир Цимлянский аңлатуынча, Россия Оборона министрлыгы контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларны сайлап алу пунктларын арттырган. Сәбәбе – махсус хәрби операциядә катнашырга теләүчеләрнең күбәюе.

Канәферләр ярдәме

«Кызыл канәфер» бөтенроссия хәйрия акциясе Татарстанда быел 20 апрельдән башлана. Бөек Ватан сугышы ветераннарына ярдәм итүгә багышланган чара бу. Аның символы сурәтләнгән истәлек значоклары, гадәттәгечә, челтәр кибетләрендә, онлайн мәйданчыклар һәм җәмәгать урыннарында сатылачак. Акцияне «Буыннар хәтере» фонды оештыра.

Истәлек значоклары сатудан кергән акча дарулар, инвалид коляскалары, колак аппаратлары, протезлар һәм ветераннар өчен кирәкле башка әйберләр сатып алуга тотылачак. Акция 22 июньгә кадәр дәвам итәчәк.

«Татар-информ»

Яңалык

Апрель үзгәрешләре

Бу айда тормышыбызга байтак кына үзгәрешләр керә. Иң мөһимнәрен туплап бирәбез.

➤Социаль пенсияләр арта. Илдә барлыгы 4 миллион чамасы пенсионерга акча өстәләчәк. Пенсия күләме бу юлы 3,3 процентка үсә.
Исегезгә төшерәбез: социаль пенсия эшли алмаучыларга (инвалидлар, туендыручысын югалткан балалар һ.б.) һәм картлык буенча иминият пенсиясе хокукына ия булмаучыларга түләнелә.

➤Торакка субсидия алу шартларын төбәкләр үзләре билгели башлый. Җирле хакимиятләр, аерым алганда, кешеләрнең керемендә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымының максималь өлешен (шуннан зуррак икән, субсидия түләнелә) билгели алачак. Төбәкләрдә икътисадый хәлнең төрлечә булуы сәбәпле, шундый карарга килгәннәр. Субсидия билгеләү хокукын субъектларның үзләренә тапшыру ярдәмне нәтиҗәлерәк итү мөмкинлеге бирәчәк. Хәзерге вакытта аны гомуми керемнең 22 процентыннан күбрәген коммуналь түләүләргә тотучылар ала.

➤Микрофинанс оешмалары клиентларын яңача тикшерә башлаячак. Бу җәһәттән Россия банкы күрсәтмәсе үз көченә керә. Документта, әйтик, кешенең үзмәшгуль булып торуын билгеләү өчен, салым түләүче буларак исәптә тору турында белешмәсен күрсәтү таләп ителәчәк. Бурычка алган акчаның кире кайтарылмау куркынычын булдырмас өчен, тикшерүне шулай кырысландыралар.

➤Инвалидлык билгеләүгә нигезләр арта. Россиядә инвалидлык билгеләүнең яңа тәртибе гамәлгә кертелүгә бәйле бу. Төп нигезләрнең берсе – хәрби операциядә үз теләгең белән катнашу контрактын үтәгәндә чир алу яки имгәнү. Биредә сүз мобилизация, хәрби хәл кертелү, коралллы конфликтлар, террорчылыкка каршы операцияләр чорында һәм армия көчен илдән читтә кулланганда коралллы көчләргә йөкләнгән бурычларны үтәүче ихтыярилар турында бара.

➤Түрәләр өчен һөнәри осталык дәрәҗәсе билгеләнә. Дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясенә карата таләпләр артачак. Алар үз һөнәре буенча өстәмә программалар үзләштерергә тиеш булачак. Шул ук вакытта дәүләт хезмәткәрләре өчен классификация имтиханы бетерелә. Хәзер түрәләрнең һөнәри осталыгын дәүләт хакимияте органнарының кадрлар хезмәтләре билгеләячәк. Моның өчен фән, мәгариф оешмаларын һ.б. җәлеп итү күздә тотыла.

➤Иминиятчеләргә кешеләрне төп мәгълүматлар белән таныштыру йөкләнә. 1 апрельдән иминиятчеләр үз теләге белән иминият килешүе төзергә ниятләүчеләрне иминиятләштерү шартлары турында төп мәгълүматлардан торган документ белән таныштырачак. Аның күләме A4 форматындагы өч кәгазь битеннән дә озын булмаска тиеш.

➤Чит илләрнең интернет-кибетләреннән товарлар тизрәк кайтарыла башлаячак. Бонд складларыннан файдалану буенча эксперимент башлануга бәйле бу. Сатучылар чит илдән кайтарылган товарны шундый складларда саклау мөмкинлеге алачак. Сатылганчы, товарга таможня пошлинасы һәм салым түләнми.

➤Банклар кәгазь акчаларны җентекләбрәк тикшерә башлаячак. Банк кассирларына өслегендәге сурәтенең ачыклыгы 6 процентка (моңа кадәр 8 процент булган) һәм күбрәк кимегән кәгазь, шулай ук тимер акчаларны клиентларга бирү тыелачак.

Сүзгә-сүз

Татьяна ГОЛИКОВА, Россия вице-премьеры:

Мәктәпләр төзелешен киләсе елга калдыру гадәтеннән арынырга кирәк. Яңа мәктәп төзелә икән, аның тиз арада кулланылышка тапшырылуы, балаларның дәресләргә йөри башлавы мөһим.

(Россия Мәгърифәт министрлыгының йомгаклау коллегиясеннән)

РОССИЯДӘ – ҖИНАЯТЬЛӘР

Россия Тышкы эшләр министрлыгы 2022 елда нинди җинаятьләр аеруча күп булганын ачыклаган.

1,97 МЛН ҖИНАЯТЬ ОЧРАГЫ
(2021 елгы саннан 2 процентка азрак)

38,3% >> башка төр җинаятьләр
35,5% >> урлау
17,4% >> мошенниклык

Россия тышкы эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча

Кызамык йоктырганнар

Татарстанда 13 кеше кызамык белән чирләгән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, сырхауларның барысы да чирне чит илләрдән, шул исәптән 11е Таҗикстаннан ияртеп кайткан. Табиблар тагын 7 кешене шиккә алган. Болары да – башка илләрдән килүчеләр.

Санитар табиб әйткәнчә, Таҗикстанда, Новосибирск һәм Төмәндә кызамык чире бик нык көчәйгән.

Любовь Авдонина искә төшереп үткәнчә, һәр очракта чир чыганагы ачыклана, чирләүченең торагы дезинфекцияләнә, аның белән элемтәгә керүчеләрнең һәммәсенә прививка ясала.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Киләчәк безгә кирәкме?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ), халыкка бик үк гадәти булмаган сорау биреп, үзенең чираттагы сораштыру-тикшеренүен үткәргән. «Әгәр дә вакыт буйлап сәяхәт итү мөмкин булса, сез кайсы дәвергә китәр идегез?» дигән сорауга респондентларның 29 проценты үткән XX гасырны сайлаган. Тагын да ераккарак – XIX гасырга халыкның – 16, XVIII гасырга 12 проценты барасы килә икән. Ә менә киләчәкне күрәсе килгәннәрнең өлеше җәмгысы 3 процент тәшкил иткән.

Процентларга карагач, кызык та, кызганыч та нәтиҗә килеп чыга. Россиянең үзенчәлекле халкына зурдан алганда, киләчәк бөтенләй дә кирәкми икән бит. Гавам үткән белән яши. Кемдер: «Киләчәк ул – билгесезлек, ә билгесезлектән курку һәрдаим бар», – дияр. Юк, ул гына түгел. Курку дигән сыйфатка кереп киткәч, шунысын да әйтәсе килә: бездәге халыкта ул күбрәк, башка кавемнәр белән чагыштырганда киңрәк колачлы кебек. Без – куркытылган, басынкы, юаш һәм көндәм кимәлгә җиткерелгән затлар. Ничекме? Куркуны өч йөз елга якын сузылган крепостное право, россияленең геномыннан аның һаман да чыгып бетмәве белән аңлатып була. Аны гасырдан артык барган кире селекциягә – кыю, мөстәкыйль кешеләрнең, үз фикере булганнарның читкә куылып, үзләре китеп торуына, йә булмаса юкка чыгарылуына – террорга, ГУЛАГка бәйләп була. Ирек-хөрлектә аз гына да яшәп карамаганлыкка сылтап була. Җыеп әйткәндә, без – шушы көннәргәчә үз язмышына үзе хуҗа булып бетә алмаган, вәкаләтләребезне җыеп, властька тапшырган халыклар арасында әле.

Вакыт буенча сәяхәт, дигәндә XX гасырны сайлауда, әлбәттә, русча ностальгия дип аталган җирсүнең, өлкәнрәк буынның үлән дә яшелрәк, кояш та яктырак, агачлар да биегрәк булган яшь чакны сагынуының да өлеше бардыр. Бүгенге өлкәннәр – шул гасырның икенче яртысында туып, бала чагы, яшьлеге Хрущев, Брежнев заманнарына туры килгән, кыйналуны, зур нужаны күрмәгән буын. Аларны аңлап була. Тик Брежнев идарә иткән, социализмга «кеше чырае» иңгән чор – XX гасырның бары биштән бер өлеше генә. Ә ВЦИОМ респондентлары гасырның башына, аның уртасына да «күчәргә» әзер. Ирексездән, шундый сорау туа: ил өчен авыр һәм дәһшәтле XX гасырга гавам ни сәбәпле ашкына, анда аңа ни калган? Һәм инде гавамга диагноз куйганчы, ул йөзьеллыкка кыскача экскурс ясыйсы, XX гасыр гади халыкка күрсәткән михнәтләрне санап чыгасы килә.

Гасырның Россия җиңелгән Рус-япон сугышы, шуңа күпмедер бәйле Беренче рус инкыйлабы белән башланып киткәнен беләбез. Дистә ел да үтмәстән, патша хөкүмәте, катнашмый калу мөкинлеге булып та, юк сәбәпне бар итеп, Беренче Бөтендөнья сугышына кереп китә. Ул канкоешның янә дә ике революция һәм властька большевиклар килү белән тәмамлануы мәгълүм. Аннан соң, болар гына аз дигән төсле, илне тетрәткән, туганны туган белән якалаштырган Гражданнар сугышы. Сугыш туктагач башланган тыныч тормыш та халыкка рәхәтлек алып килми – продразверстка, ягъни крестьянны талау сәбәпле яралган коточкыч ачлыклар. Аны кичеп, халыкның тамагы туярга да өлгерми – мәгез, кабул итеп алыгыз, дигәндәй, гавам өстенә Зур террор дип аталган фаҗига ябрыла. Ул гарасаттан мантымас борын, дүрт елга сузылган, 27 миллион кешенең башын ашаган Бөек Ватан сугышы. Сугыштан соңгы ачлык һәм ялангачлыклар. Әле Гагарин галәмгә очкан 1961 елда да, язып торуларынча, халык чабатасын тулысынча салмаган була. Бары шул еллар тирәсендә генә гади кеше «пенсия» дигән хикмәтле сүзне ишетә, авыл кешесенә кенәгәдәге таяк урынына такы-токы булса да хезмәт хакы түли башлыйлар. Кешелекле Брежнев чоры, Горбачев «перестройка»сы үтүгә, тагын мәхшәр – талаулы приватизация, кассада янган акчалар, эшсезлек, ике чечен сугышы һ.б.

Егерменче гасырда шулкадәр михнәт күргән башка халык тагын бар микән? Һәм, ни гаҗәп, россияле кавемнең шунда кайтасы килә. Саналган җәберләрне тагын бер кат үтү өченме? Без кемнәр – мазохистлармы әллә? Анысы да юк түгелдер. Тик төп диагноз, миңа калса, наданлыкта, надан романтизмда, тарихны белмәү, аннан сабак алмауда, үткәнгә битарафлыкта ята. Үткәнгә пропаганда призмасы аша, алсу күзлек киеп карауда…

Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүчеләр респондентлардан әле тагын: «Үткәндәге кайсы шәхесләр белән аралашып алырга теләр идегез?» – дип тә сораган. Халыкның 17 процентының – Петр I, 15 процентының – Сталин, 7 процентының Ленин һәм Екатерина II белән гәп куертып аласы килгән. Сорау туа: халыкны изгән, җәберләгән, сугышка куган ул патша, ул коммунистик лидерлар гади кешегә нигә? Нигә халыкның Толстой, Достоевский, Гоголь белән әңгәмә корасы килми? Тагын да шул тар маңгайлык, гыйбадлык аркасындамы? Ник исемлектә Ломоносов, Менделеев, Чайковский юк? Гаҗәп халык без. Тагын Пушкин прозасы – алпавыт Троекуровның атна саен ат абзарында сыртлары каезланган крепостнойлары искә төшә. Аларның: «Безнең хуҗа тирә-як бариннар арасында иң гаяре, иң кәттәсе, берсенә дә баш бирми», – дип горурлануы.

ВЦИОМның ул сораштыруы сораштыру гына түгел. Аннан шактый кызык нәтиҗә дә чыгарып була. Юләр юрап китерер, ди. «Сез мәхлукларга үткән кирәкме? Булачак, өлешчә алачаксыз сез аны – үткәнгә охшаш көннәрне! Сез аларны инде күпмедер алгансыздыр да. Алсагыз – тәмен, рәхәтен күрегез! Киләчәк сезне кызыксындырмый икән…» Күкләр шулайрак та фикерли, эшли ала бит. Без шушы XXI гасырда яшәргә хөкем ителгән. Өлкән туган әйтмешли: «Времена не выбирают, в них живут и умирают». Яшәмәслек түгел. Ат абзарында беребезне дә дилбегә белән ярмыйлар. Күңелдә шом яшәсә дә, тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Үткәнгә түгел, киләчәккә, аның да шомсызына карап гомер итик!!!

XX гасыр тарихына, дөнья тарихына, бүгенгегә карап, тагын шуны әйтергә була: кеше дигән затсыз җан иясе тыныч, ипле яши белмәгән һәм белми. Шуңа күрә тиз араларда дөнья рәтләнер, акылга килер, дип өметләнеп булмый. Тик бөек фаҗига, зур тетрәнүләр юрау да дөрес түгел. Дөнья бары тик катлаулана, анда ыгы-зыгы арта. Барыннан да нык артканы – мәгълүмат. Без кешене аяктан егар, акылдан яздырыр дәрәҗәгә җиткән мәгълүмат ташкыны шартларында яшибез. Шундый мәлләрдә һәр «әпчхи»гә игътибар биреп, аларны җыеп, глобаль тискәре нәтиҗәләр чыгару да – гөнаһлы шөгыль. XXI гасырның, катлауланса да, XX гасыр күрсәткән дәһшәтләрне китермәсенә мин ышанам.

ИСКЕ ЯҢА БУРЫЧЛАР

Хөкүмәт йортында

Караш башка, эш шул ук. Татарстанда телләр турындагы законны гамәлгә ашыру буенча совет утырышында республикада ике дәүләт теленең ни дәрәҗәдә тигез файдалануын тикшерделәр.

tatarstan.ru

Уңай үзгәрешләр дип, башкарма хакимият органнарының халык гозерләренә татарча җавап бирүләрен әйтергә була. «Авырткан» җир булып исә һаман да элмә такталар кала икән. Шулай ук рәсми сайт һәм аккаунтларда мәгълүматларның күпчелеге урысча булу да – элеккеге баш бәласе.

2022 елда башкарылган эшләр өчен Татарстанның юстиция министры Рөстәм Заһидуллин хисап тотты. Министр әйтүенчә, былтыргы саннар 2021 елгы күрсәткечләрдән күпкә яхшырак. Саннарга күз салыйк соң.

Хакимият органнары былтыр 80 меңнән артык халык мөрәҗәгатен караган. Җирле үзидарә вәкилләре – 50 меңнән артык. Аларга язмача, мөрәҗәгать иткән телдә җавап кайтарылган.

Былтыр Татарстан халкы хакимият органнарына татарча ешрак мөрәҗәгать иткән. Андый мөрәҗәгатьләр 252 процентка арткан! Сөендергәне шул: җавап көтүчеләр аны татар телендә алганнар. Әйтик, 2021 елда башкарма хакимият органнары татар телендә 2,6 мең җавап кайтарса, былтыр бу сан 11,3 меңгә җиткән.

Җирле үзидарә органнарына да татарча гозер белән киләләр. Әмма бу күрсәткеч чагыштырмача зур түгел. 2021 елда 780 мөрәҗәгать кабул итсәләр, былтыр – 881.

Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, 2018 елдан министрлык дәүләт телләренең үтәлешен 15 төрле күрсәткеч буенча бәяли. Әйтик, юридик сорауларга татар телендә җавап алучылар, урамнарда ике телдә дә урнаштырылган элмә такталар, туган телдә укучы балалар өлеше һәм башкалар. Былтыр шушы күрсәткечләрнең җидесе 100 процентка үтәлгән.

Республиканың ике дәүләт телен тигез файдалану буенча ким күрсәткечләр түбәндәге юнәлешләрдә чагылган: татар телендә театраль тамаша чаралары (51,8 процент), мәктәпкәчә учреждениеләрдә татар телен укыту (56,3 процент), вокзал һәм аэропортларда ике дәүләт телендә дә мәгълүмати хезмәт күрсәтү (69 процент), җәмәгать транспортында мәгълүмат бирү (автоинформатор) (89,5 процент). Транспорт җәһәтеннән, Алексей Песошин бу мәсьәләне хәл итәргә, урамдагы күрсәткечләрне тәртипкә китерергә кушты.

Планлы күрсәткечләргә ирешмәгән юнәлешләр рәтендә хакимият органнары һәм район сайтларында татарча мәгълүматның аз (йә юк) булуын атадылар. Хезмәт күрсәтү предприятиеләре дә мәгълүмати икетеллелеккә битарафрак карый (98,6 процент).

Кыскасы, бу юлы да Хөкүмәт йортында иске яңа бурычлар куелды. Үтәлешен киләсе елда бергәләп бәяләрбез.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Мөмкинлекләр чыганагы

Илкүләм проектлар, дәүләт программалары һәм партия проектлары халыкның тормышын яхшырту өчен муниципалитетларга, шәһәр-районнарга өстәмә акча җәлеп итү мөмкинлеге бирә. Дәүләт Советында «Бердәм Россия» Татарстандагы төбәк бүлегенең партия проектларын тормышка ашыру комиссиясе утырышында шул хакта сүз барды. Дәүләт Советы Рәисе, партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россия»нең федераль һәм төбәк проектлары координаторлары, иҗтимагый советлары рәисләре белән очрашты.

– «Бердәм Россия» дәүләт программаларын, илкүләм проектларны, шулай ук партиянең үз проектларын тормышка ашыруга гаять зур әһәмият биреп килә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Аларның муниципалитетларга, шәһәр-районнарга өстәмә акча җәлеп итү мөмкинлекләре бирүен искәртеп, бу эшне көчәйтергә өндәде. Аның әйтүенчә, бер проектта катнашмаган муниципалитетлар да бар әле.

Партия проектлары республикада 2006 елдан бирле тормышка ашырыла. Башлыча алар кешеләрнең депутатларга мөрәҗәгатьләреннән, сайлаучылар наказларыннан чыгып эшләнгән. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, бу проектлар «Халык программасы» (сайлаучыларның 2,5 миллионнан артыгы тәкъдимен берләштергән) белән бергә «эшли».

Хәзерге вакытта Россиядә 24 федераль партия проекты гамәлгә ашырылып килә. Татарстан аларның барысында да катнаша. Соңгы вакытларда проектлар федераль башкарма хакимият органнары белән тыгыз элемтәдә хәл ителә. Күбесенең иҗтимагый советлары рәисләре итеп федераль министрлар билгеләнгән. Проект эшчәнлегенә төбәкләр башлыклары, Дәүләт Думасы депутатлары, сенаторлар җәлеп ителгән. Әйтик, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Шәһәр мохите» федераль партия проектының иҗтимагый советы рәисе булып тора.

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, республикада да башкарма хакимият органнары белән шундый ук эш алып барылырга тиеш.

Проект эше кысасында якын араларда берничә чара үткәрү күздә тотыла. Мәсәлән, 27 апрельдә «Җиңү диктанты» узачак. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган халыкара тарихи диктант бу. Акция быел инде бишенче тапкыр үткәреләчәк. «Чиста ил» проекты кысасында, гадәттәгечә, өмәләр булачак.

Утырыш азагында Фәрит Мөхәммәтшин республикада партия проектларын тормышка ашыру мәсьәләләрен аерым контрольгә алырга кирәклегенә басым ясады.

БАЛА СЫНАЛГАН ЧАК

Көн кадагында

Көтмәгәндә әтисез яшәргә мәҗбүр булган сабыйлар хәзер кабат әтиләре белән бергә яшәргә өйрәнә. Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр гаиләләре янына ялга кайта башлагач, психологларга ярдәм сорап килүче гаиләләр саны арткан. Белгечләр исә бу хәлгә гаҗәпләнми. Тормыштагы шатлыклы вакыйгалар да, борчу-хәсрәте дә – бала психикасы өчен зур сынау, ди алар.

«Ышаныч» психология үзәге җитәкчесе Наталья Сабирова сүзләренә караганда, узган елның ноябреннән бирле үзәккә мобилизациягә эләккән егетләрнең якыннарыннан килгән мөрәҗәгатьләр саны кискен арткан. Аларның, нигездә, барысын да бер сорау борчый. «Әтисе белән яшәп өйрәнгән баланы хәзер ничек тәрбияләргә, ничек үстерергә?» – дип өзгәләнә аналар.

– Ярдәм сорап килгән әниләргә бу вакыйгаларның вакытлы күренеш булуын, аны булдыра алган кадәр сабыр гына уздырырга кирәклеген аңлатабыз. Кара-каршы утырып, мондый шартларда баланың психикасына зыян китермичә тәрбия бирү, аның ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлларын эзлибез. Баланың әтисе белән элемтәне өзеп бетермәве, мөмкинлек булганда телефоннан аралашып торулары мөһим, – дип сөйләде белгеч журналистлар белән очрашуда. – Соңгы арада безгә шактый гаҗәп мөрәҗәгатьләр килә башлады. Көтмәгәндә әтисез яшәргә мәҗбүр булган сабыйлар хәзер кабат әтиләре белән бергә яшәргә өйрәнә. Әтиләре озак вакыт өйдә булмаганлыктан, алар үзләренчә көн күреп өйрәнгән бит инде. Хәзер аларга, вакытлыча булса да, элеккеге яшәү рәвешенә кайтып алырга туры киләчәк. Шатлыклы вакыйга булса да, бала психикасы өчен ул – зур сынау.

Белгечләр күбрәк шунысы өчен борчыла. Яшерен-батырын түгел: замана баласының холык-фигыле, психик ныклыгы болай да мактанырлык түгел. Яшьләр, бигрәк тә яшүсмерләр арасында суицид очракларының елдан-ел арта баруын башкача тагын ничек аңлатасы? Татарстан Балалар омбудсмены Ирина Волынец сүзләренә караганда, соңгы ике елда республикада үсмерләр арасында үз-үзенә кул салу очраклары ике тапкыр арткан. Чагыштыру өчен: 2020 елда республикада шундый 11 очрак теркәлгән булса, 2022 елда инде ул сан 22гә җиткән. Бу соңгы биш елдагы иң зур күрсәткеч дип бәяләнә.

Психологка мөрәҗәгать итүчеләр дә күбәйгән. Узган ел Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) бу уңайдан махсус тикшерену уздырган. Бүген яшьләрнең 35 проценты, ил күләмендә халыкның 15 проценты психологик ярдәмгә мохтаҗ, ди белгечләр. 2009 елда ил халкының нибары 6 проценты гына психологларга йөрсә, узган ел андыйлар саны 12 процентка җиткән.

– Үсмерләр арасында психологик киеренкелектә яшәүче, күңел төшенкелегенә бирелүчеләр күп булу киләчәктә суицид килеп чыгу куркынычын бермә-бер арттыра. Кызганыч, үз-үзенә кул салу очраклары буенча Россия – бүген алдынгы илләр рәтендә. Яшьләрдә психологик ныклык юк. Еш кына алар тискәре күренешләргә ничек каршы торырга белми, югалып кала, – ди омбудсмен.

Республика балалар клиник хастаханәсе психологы Лилия Горохова фикеренчә, бүген психикасы нык булып тоелган баланың да бик тиз сынуы ихтимал.

– Көндәлек тормыштагы стрессларга алар да чыдамаска мөмкин. Ник дигәндә, алар мондый очракта үз-үзенә ничек ярдәм итәсен белми. Хәзер күп кенә ата-ана баласын артык саклап-яклап үстерә. Аңа үз хаталарында өйрәнергә, тышкы «һөҗүм»нәргә каршы торып, чыныгырга мөмкинлек калдырмый. Суицидка барган үсмерләр арасында да җитеш тормышта, үрнәк гаиләдә тәрбияләнгән, беренче карашка бернинди борчуы юк сыман тоелган балалар шактый. Психологларның хәзер аеруча кирәк чагы. Халыкның психологик белем дәрәҗәсен арттырыр чак, – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Авыл эшмәкәрләре

ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВЛАР:

«СӨТНЕ АЛМАСАЛАР, ЗАВОД ТУКТЫЙ»

Балтач эшмәкәрләре Гөлүзә һәм Данил Гыйләҗетдиновлар шулай ди. Уйлап, әйтеп кенә калмый, үзләре оештырган сөт җыеп эшкәртү белән шөгыльләнүче кооператив ачканнар.



Гыйләҗетдиновларның шәхси архивыннан

– Эшмәкәрлеккә без 2008–2009 елларда керештек. Беркем юнәлеш тә бирмәде, өйрәтүче дә булмады. Ирем белән икебезнең дә бер теләк бар иде: үз көнебезне үзебез күрергә, гаиләбезне муллыкта яшәтергә. Бу теләгебез бик зур иде, тик акча гына юк. Әти-әниләрдән дә ярдәм көтеп булмый, алар икесе дә – авыл кешеләре. Үзебезгә тырышырга, нәрсәдер эшләргә кирәк дигән уртак фикергә килдек, – дип, хатирәләргә бирелә Гөлүзә. – Хәзер ул чакларны искә төшерсәм, башларым әйләнеп китә. Ике бала: берсенә – 7 яшь тирәсе, икенчесенә ике яшь тә тулмаган. Данил белән икебез дә – дәүләт эшендә. Аннан кайткач, кичен авылларга тире җыярга чыгып китә идек…

Гыйләҗетдиновларга иң беренче өстәмә акча нәкъ менә тире җыюдан керә. Өйгә кайткач, плюсларын-минусларын саныйлар, аз булса да акча кергәнен белеп сөенәләр. Шул язда исә тире җыйнау белән беррәттән чебеш-бәбкәләр дә алып кайтып сата башлыйлар. Гөлүзә заявкалар җыя, Данил кошчылык фабрикаларына йөри. Кич белән клиентларга илтеп бирәләр. Менә шул акчаларны туплап, 2010 елда өйләренең фундаментын салалар.

Шул елны Данил, төп эшен ташлап, үзенең туган авылы Борнакта сөт җыя башлый. «Ул бик үҗәт, бер эшне башласа, көнен-төнен оныта, шушы еллар эчендә мин аның бер тапкыр да арыдым дигәнен ишеткәнем булмады, – ди бүген Гөлүзә. – Сөт бит ул үзе дә шундый юнәлеш: анда тынычлык та, йокы да юк… Мин дә Данилга булышырга тырыштым, бөтен документларны тәртипләп алып бардым. Данилның кешеләр белән бик ипле сөйләшүе, гаделлеге эзсез калмады: аны күрше авыллар да чакыра башлады. Шулай итеп, бизнесыбыз көнләп үсте. Мин дә, бик күп уйлаганнан соң, район мәгариф идарәсендәге эшемне ташлап, туган авылым Салавычта, күрше Яңа Салавычта сөт җыя башладым. Иске генә «каблук» – «Москвич» машинабыз бар иде – шуның әрҗәсенә мичкәләр утыртып чыгып китә идем. Иртәнге өчтә Данил «УАЗ»ик белән, мин «Москвич»та юлга кузгалабыз. Без сөт җыеп, сөт-май комбинатына илтеп кайтканчы, балалар үзләре йокыдан тора, ашый, бер-берсенең чәчләрен үрә, киенеп, мәктәпкә китәләр иде. Алар шуңа күрә кечкенәдән мөстәкыйль булып, муллыкның күктән ишелеп төшмәгәнен аңлап үсте. Утыз градуслы салкынмы, эссеме, буранмы, яңгыр коямы – без тугыз ел көн саен шушы режимда эшләдек, яшәдек…»

Бер тоннага якын сөт җыюдан башлаган Гыйләҗетдиновларга сөт тапшыручы авыллар, хуҗалыклар саны арта барып, алар 20 тонна чигенә җитә. Хөкүмәтнең кооперативларга ярдәм итә торган программасы барлыгын белеп, 2019 елда алар да кооператив төзи. Барысы да шома гына барса, билгеле, тормыш булмас иде. Нәкъ шушы елны хуҗалыкларында янгын чыгып, шактый гына матди зыян килә, өстәвенә көндәшлек тә бик көчәя. Бер танышлары сөтне суытып сатарга, төрле заводларга элемтәгә чыгарга киңәш бирә. Нәрсәнедер үзгәртергә кирәген аңлаган Гыйләҗетдиновлар бу мөмкинлекне ычкындырмый: танк дип йөртелүче 4 тонна сыйдырышлы суыткыч цистерна сатып алалар. Бераздан 8 тонналысын… Бу бик дөрес адым була.

2021 елда инде Гөлүзә белән Данил яңа хыяллар белән яши башлый: җыйган сөтне үзебездә эшкәртеп, май ясап булса иде, ди алар. Уйлап кына калмыйлар, республика конкурсында катнашалар. Тик ул елда грант ота алмыйлар. Әмма Гыйләҗетдиновларга бу да киртә булмый: зур күләмдә кредит алып, 2022 елда алар модульле мини-заводның бинасын корып куя, тагын грант өчен конкурста катнаша… Бу юлы бәхет елмая. Завод эченә кирәкле җиһазлар әнә шулай алына. Быел февраль башында алар беренче продукцияләрен чыгара.

Бүген аларның мини-заводы 32 тоннага кадәр сөт кабул итә ала. 20 тонна сөт кабул ителә, 10 тоннасы эшкәртелә, көндәлек 1 тонна атланмай ясыйлар.

– Без бит шәхси хуҗалык сөтеннән генә ясыйбыз, аларның сыйфаты бик югары, ни дисәң дә, шәхси хуҗалык сыерлары өстәмә катнашмаларсыз, табигый ризык ашый… Майны ясарга өйрәндек, инде сатарга да өйрәнәсе бар, – ди Гыйләҗетдиновлар. – Сөтне дә 30 сәгать кенә саклап була. Май ясаганнан калган аертылган сөтне дә урнаштыра барырга кирәк. Әлегә без аны 300 километрга үзебез илтеп бирәбез. Ул сөтне алмасалар, безнең завод туктый. Шуңа күрә бу проблеманы үзебездә хәл итү юлларын табарга кирәк. Юнәлешләре бар, әлегә бөтенесен бергә колачлап булмый…

Мини-завод дисәң дә, проблемалары зур заводныкыннан ким түгел, мәшәкате чыгып кына тора, диләр. Тикмәгә генә: «Олы йортка ни кирәк, кече йортка шул кирәк», – димиләр бит.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КИРЛЕМӘННӘР КИРӘК

2 АПРЕЛЬ – ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР КИТАБЫ КӨНЕ

vk.com

Бәйрәмнең бу көндә билгеләнеп үтүе очраклы түгел. Бөтен дөнья балалары яратып укый торган әкиятләрнең авторы Ганс Христиан Андерсен 1805 елның 2 апрелендә туган. Дания язучысының тылсымлы әкиятләрен менә инде берничә буын укып үсә. Ә татар балалары йотлыгып укырлык милли әсәрләр бармы? Татар балалар әдәбияты бүген ни хәлдә? Без әнә шуны белештек.

Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр редакциясе һәм махсус проектлар бүлеге җитәкчесе Айсылу Галиева әйтүенчә, Татарстан китап нәшриятында сатыла торган китапларның 70 проценты – балалар әдәбияты.

– Ихтыяҗ бар, әлбәттә. Әйтик, безнең нәшриятта 100 китап сатылса, шуның 70е – балалар китабы. 6–7 ел элек белән чагыштырганда азрак, әмма сатыла. 2017 елда мәктәпләрдә татар теле дәресләре азайганнан соң, татар китабын укучылар күзгә күренерлек кимеде. Элек балалар китаплары 5әр мең тираж белән чыга иде. Хәзер 3 мең тираж белән чыгарабыз икән, Аллага шөкер, дибез, – ди Айсылу Галиева.

Балаларны иң күбе дидактик карточкалар, Абдулла Алиш, Габдулла Тукай әсәрләре кызыксындыра икән. Шулай ук иң күп сатылган китаплар арасында төймәле китаплар, энциклопедияләр дә бар.

– Замана баласына интерактив китаплар кирәк. Бала укый да, карандаш тотып эшли дә алсын. Энциклопедияләргә, төймәле китапларга ихтыяҗ зур, бик яратып укыйлар. 2020 елда ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ябык әдәби конкурс үткәргән иде. Шушы конкурста җыңгән шигырьләр, хикәяләрнең бер өлешен балалар өчен җыентык итеп бастырып чыгардык. Ә быел конкурста җыңгән әсәрләрне һәрберсен аерым китап итеп чыгарырга ниятлибез, – ди Айсылу Галиева.

Балалар әдәбиятына ихтыяҗ һәрвакыт булган һәм булачак. Язучы, Муса Җәлил премиясе лауреаты Рөстәм Галиуллин әнә шундый фикердә.

– Бу табигый да, чөнки баласының киләчәген якты итеп күрергә теләгән һәр ата-ана әле карында чакта ук аңа бишек җыры көйли, әкият сөйли. Минем фикеремчә, иң кече яшьтәге балаларга әнә шул әти-әни, әби-бабай сөйли торган әкиятләр, тәрбияви хикәяләр, шигырьләр безнең әдәбиятта тиешле дәрәҗәдә бар. Аның заманнан арттарак калганнарын әти-әниләр үзгәртеп тә сөйли ала. Ә менә 9–13 яшьлек балалар өчен – үзләре кызыксынып укучыларга кызыклы, мәгълүматлы, маҗаралы заманча әсәрләр бик аз, – ди язучы. – Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге комиссия уздырган әдәби бәйгедә дә иң аз эшләр яшүсмерләр әдәбияты (хикәя, повесть, шигырь) номинацияләрендә булган иде. Минем балачактан, мисал өчен, Кирлемән исемле үзенчәлекле герой истә калган. Аның китабы да, телевизион фильмы да бар иде. Балалар әдәбиятына заманча геройлар җитми. Һәм ул геройлар балаларны кызыксындырсын өчен, ул әсәр, китап булудан тыш, мультфильмга, фильмга, сувенир продуктка да әверелергә тиеш.

Балаларны кызыксындырырлык заманча геройларны каян табарга соң? Рөстәм Галиуллин, бу мәсьәләне чишүдә махсус проект ярдәм итәчәк, ди:

– Соңгы вакытларда «Туган батыр» дигән геройны популярлаштыралар. Бу – бик яхшы эш. Ләкин бүгенге заманда бу үзе бер индустрия булырга тиеш, аны язучы гына популярлаштырып, булдырып бетерә алмый. Минем фикеремчә, язучы, продюсер, режиссер, әти-әниләр, балалар белән берлектә заманча татар героен «тудыра» торган махсус проект кирәк, – ди язучы.

Күпләр: «Замана баласы китап укымый, китапханәләргә йөрми, телефонда гына утыра белә», – дияргә ярата. Түбән Кама шәһәренең үзәкләштерелгән китапханәләр системасының методик бүлеге мөдире Роза Аникина исә моның белән килешми. Балалар китапханәләренә элеккегә караганда бүген кызыксыну тагын да күбрәк, дип саный ул.

– Ни өчен дигәндә, хәзер китапларны матур иттереп, балаларны кызыктырырлык итеп чыгаралар. 3D форматлар, зур-зур рәсемнәр, төрле технологияләр кулланыла. Ничек итеп кенә ясамыйлар бит хәзер китапларны! Каникулда мәктәп укучыларына укыр өчен китаплар исемлеге төзеп бирәләр. Безнең «Апуш» үзәк китапханәсендә балалар чират тора! Китапларыбыз яңарып тора. Татарстан китап нәшрияты да бик булыша. Балалар китапханәләре һәм китаплары ул кадәр үк аяныч хәлдә дип әйтмәс идем, – ди Роза Аникина.

Балалар шагыйрәсе Йолдыз Шәрәпова исә, язучыларга балалар әдәбиятына күбрәк игътибар бирергә кирәк, дип саный:

– Балалар әдәбиятына ихтыяҗ булмаса, әдәбиятка бөтенләй ихтыяҗ булмый дигән сүз. Әдәбиятның нигезен балалар әдәбияты тәшкил итә. Бүген аның торышы начар дип әйтмәс идем. Хәзер укыла икән, 10 елдан, 20 елдан соң да укылачак ул. Элек-электән балалар әдәбияты җитди түгел, анда такмак язучылар гына, дигән фикер йөргән. Дөрес түгел бу. Бала булмаса, ана булмый. Башта балалар турында кайгыртырга кирәк. Алар – безнең киләчәгебез, – ди шагыйрә. – Ленар Шәех, Рифат Сәлахов заман балаларына туры килә торган әсәрләр иҗат итә. Язучылар бар инде ул. Куркыныч башка нәрсәдә: хәзер мәктәпләрдә татар теле бик аз укытыла. Аның белән генә әдәбиятны саклап калып булыр микән? Туган телен атнасына ярты, бер сәгать укыган баладан язучы чыкмаячагы көн кебек ачык. Балаларны җәлеп итү максатыннан без, язучылар, балалар бакчаларына йөри башладык. Шундый чараларга күбрәк йөрергә, күзләренә күренергә, кызыктырырга кирәк дип саныйм. Теләп, яратып эшләсәң, юллары табыла.

Ләйсән САФИНА

АЛИНӘ ШӘГӘРӘЕВА:

«ДӘРЕСТӘН ЦИРК ЯСАРГА КИРӘКМИ»

Туган телеңне белмәү оятмы? Өй эшләре, дәреслекләр авыр булганга кем гаепле? Әлеге һәм башка сораулар турында 2023 елның иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып танылган Алинә ШӘГӘРӘЕВА белән сөйләштек. Ул Казанның 13 нче гимназиясендә белем бирә.

:: Алинә Илсуровна, сез – авыл мәктәбендә укытып, шәһәргә килгән укытучы. Кайсында белем бирү авыррак?

– Мин Спас районының Урта Йорткүл авылыннан. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, белем алуымны башкалада дәвам иттердем. Кызганыч, безнең мәктәптә чит тел укытмадылар, чөнки укытучы юк иде. Инглиз телен өйрәнү теләге белән Татар дәүләт гуманитар институтының чит телләр факультетына укырга кердем. Анда «инглиз теле, татар теле һәм әдәбияты» белгечлеге алдым. Әти-әни бик сагындырган иде, шуңа авылым мәктәбенә кайтып урнаштым. Чит тел укытучылары җитми, шуңа күрше авылларга да йөреп, берничә мәктәптә эшләргә туры килде. Авыл мәктәпләрендә балалар саны кимү сәбәпле, 2012 елда Казанга килдем. Туган телемә булган мәхәббәт, бай әдәби мирасыбыз белән кызыксынуым өстенрәк чыкты. Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназиядә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башладым.

Авыл һәм шәһәр баласы арасында аерма бар, әлбәттә. Тик ул хәзер без үскән чордагы кебек үк кискен түгел. Аерма күбрәк холык, тәртиптә чагыла кебек. Авыл баласы беркатлырак инде ул, һәм, авыл булгач, бер-береңне беләсең, бер зур гаилә кебек якын буласың.

Хәер, мин эшләгән гимназия дә артык зур түгел. Һәр баланы, әти-әнине беләбез диярлек. Шуңа күрә зур гаилә кебек яшибез. Әти-әниләр балаларына безнең гимназияне очраклы гына сайламый. Беренчедән, бездә татар мохите. Икенчедән, ата-ананың күңеле тыныч, чөнки бездә тәртип.

:: Татар гимназиясе булгач, барлык фәннәр дә туган телдә укытыламы?

– Сер түгел, татар гимназиясе булсак та, бездә татарлар гына түгел, башка милләт балалары да белем ала. Таләпләр буенча, гимназиягә килгән, безнең микрорайонга кергән һәр баланы алырга кирәк. Шул сәбәпле хәзер кайбер фәннәр рус телендә укытыла. Шулай да бер генә укучының да, әти-әнинең дә: «Безгә татар теле кирәкми», – дип әйткәне юк. Туган телне сайлау вазгыяте килеп туган чорда да бернинди ыгы-зыгы купмады. Ата-аналар һәм укучылар барысы да татар телен яклап чыкты. Шул рәвешле, татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр арасында чит милләт балалары да бар. Моннан тыш тәрбия чараларын, күпчелек түгәрәкләр, дәрестән тыш эшчәнлекне татар телендә алып барырга тырышабыз. Җитәкчебез Ләйсән Галләметдинова укытучыларга ике дәүләт телен дә камил белүне шарт итеп куя, чөнки гимназиядә аралашу мохите татарча.

:: Соңгы елларда башка фәннәргә караганда, туган телне укыту авыррак булу турында еш ишетергә туры килә. Әти-әниләр, өй эшләре катлаулы, балаларга булыша алмыйбыз, дип зарлана. Бу чынлыкта да шулаймы?

– Бәлки үзем татар гимназиясендә эшләгәнгә күрәдер, мин моның белән бик үк килешеп бетмим. Рус мәктәпләрендә, әлбәттә, проблемалар бардыр да. Ләкин бүген һәр укытучы үз фәнен өйрәнүне кызыклы гына түгел, нәтиҗәле итәргә омтыла. Баланы кызыксындыру өчен, дәрестән цирк ясарга кирәкми. Минем фикеремчә, укучыларның фән белән кызыксынуына иң төп ачкыч – укытучы осталыгында.

Өй эшләренә килгәндә, бу мәсьәләдә проблемалар барлыгын беләм. Катлаулы биремнәр булганда, үземә дә туганнарым яисә танышларымның балаларына ярдәм итәргә туры килә. Укытучы тарафыннан җибәрелгән хилафлыклар аркасында, балада һәм әти-әнидә туган телгә карата нәфрәт барлыкка килә. Укытучы һәр эшкә

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА 2023 УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

иҗади якын килергә тиеш, дип саныйм. Укучыларыма дәрестә яхшылап аңлап киткән, өйдә үзләре генә дә эшли ала торган биремнәр бирү яклы. Өй эшен аңлатканда кат-кат әйтәм: «Аңлап китәсезме, эшли алырсызмы? Эштән арып кайткан әти-әниләрегезне борчырлык булмасын».

:: Ана телеңне белмәү оятмы?

– Монысы – намус эшедер, мөгаен. Туган телне милли үзаң белән бербөтен итеп карар идем. Туган телеңне белми торып, «мин – татар!» дип күкрәк кагу дөресме? Әйе, сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Ләкин үз милләтеңне хөрмәт итсәң, туган телеңне дә белү, өйрәнү кирәк. Безнең горурланырлык бик борынгы һәм бай тарихыбыз, дөньякүләм данлыклы шәхесләребез бар. Һәм бу горурлык хисен бала күңеленә, беренче чиратта, әти-әни, әби-бабай сеңдерергә тиеш. Ләкин ни кызганыч, алар еш кына үзләре дә, баласы, йә оныгы белән вата-җимерә русча сөйләшеп маташа. Бу – баланы артык иркәләүдәндер, мөгаен. Монысы инде – башка мәсьәлә.

:: Укытучыга хөрмәт бармы?

– Бүген җәмгыять, бик күп җаваплылыкны үз өстеннән төшереп, укытучы җилкәсенә ташлый. Еш кына укытучы әти-әни өйрәтмәгәнне өйрәтергә, әти-әни бирмәгән тәрбияне бирергә, гаиләдә бала күңеленә сеңдерелмәгән кыйммәтләрне аңлатырга, ә кайвакыт әти-әни хатасын төзәтергә дә мәҗбүр. Шуңа күрә җәмгыятебезнең киләчәге нинди булуда укытучының роле әйтеп бетергесез зур. Киләчәгебез нинди булыр, илебез язмышы ничек язылыр, тарихыбыз ничек үзгәрер – болар барысы да җәмгыятебезгә нинди кешеләр килүдән тора. Ә ул кешеләрне заман укытучысы тәрбияли. Һәм без бу җаваплы вазыйфаны намус белән үтәргә тиеш. Бу – безнең миссия. Үзебез сайлаган язмыш.

Сәрия МИФТАХОВА

Ватан хакына

ЯЛГА КАЙТКАН АРСЛАН ХӘЙРЕТДИНОВ:

«Әниемнең токмачлы ашын сагындым»

Махсус операциядәге егетләр ике атналык ялга кайта башлады. Яшермиләр, бик сагынганнар. Якыннарын гына түгел, туган якның искән җиленә кадәр юксынып кайтканнар. Казанда яшәп, Югары Осланда эшләсә дә, 34 яшьлек Арслан Хәйретдиновны Буа хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциягә алалар.

Нәни улын, хатынын, әти-әнисен калдырып китү җиңел булмый аңа. Ул да башкалар юлын үтә. Башта «Казан ЭКСПО»га эләгә. Анда бер ай хәрби әзерләнү үткәч, юлга кузгалалар. Ул эшләгән мәктәп директоры шалтыратып, сиңа бронь бирәләр, дип тә әйтеп карый. Арслан дус егетләрен ташлап китә алмый. Аңлый ул: әгәр бөтен кеше дә шулай эшләсә, илне кем саклар? Гаиләңне, якыннарыңны яклаучы табылырмы?

– Мин ул чакта укыта идем. Повестка килгәч, ике дә уйламыйча, чыгып киттем. Хәрби хезмәттә булган егет бит мин. Күңелемдә ватанпәрвәрлек яши. Ничек инде чакыргач, качып йөрим? Бу минем өчен хурлык булыр иде. Беренче вакытта әти-әни дә, гаиләм дә елады. Үземә дә кыен булды. Ә инде анда баргач, бөтенләй башка дөньяга эләгәсең. Еларга вакыт юк анда, – дип сөйли Арслан. – Гаиләм, 5 яшьлек улым минем белән горурлана. Авылдан да берүземне, вуздагы укыган төркемнән дә берүземне алдылар. Димәк, шулай язган. Үзем дә хәзер махсус операциягә китүем белән горурланам. Ир булып тугансың икән, ир булырга кирәк. Әни, хатын, апа-сеңелләребез безгә ышана. Ничек инде бармый каласың?! Кайберәүләрдә ватанпәрвәрлек юк дип саныйм мин. Ватанпәрвәрлек туган якны ярату гына түгел әле ул, гаиләңне дә ярату. Телевизор карап, интернетта утырып кына ватанны саклап булмый. Әти-әниләр дә улларын армиягә җибәрмәү юлларын эзли. Хәзер бар да башкача. Егет белән егет гаилә кора, әни тәрбиясе генә алган җебегән уллар үсеп килә. Егет кеше мылтык тота белергә тиеш. Әлегә ярый безнең буын бар. Алга таба ни көтәргә?! Әмма өмет бар – этиләре махсус операциядә булганнарның уллары чын ир-ат булып үсәр дип өметләнәм.

Кайтканына өч көн узса да, Арслан әле ныклап ял итмәгән. Аны күрергә теләүчеләр, кунакка дәшүчеләр күп икән. Барлык туганнары, дуслары килеп җиткән. Әмма иң кадерле кешеләре гел янәшәсендә.

– Беләсезме нәрсәне сагындым? Әниемнең токмачлы ашын ашыйсым килде. Көткәннәр. Табын тулы ризык иде. Әниемнең тәмле ашларын да ашарга насыйп булды. Очрашу мизгелләре әле дә күңелемдә тора. Кадерле кешеләремә чәчәк бәйләмнәре алып кайттым. Әмма иң зур бүләк – йөрәктәге хисләрем. Алары әйтеп бетергесез. Чит җирдәге хәлләр мине үзгәртте, – ди Арслан.

Солдат тормышы бөтенләй башка. Махсус хәрби операция барган урында инде сайланып торып булмый. Өс киемнәрен юа алмыйлар, чиста да йөриселәре килә. Әнә шуңа алып килгән киемнәрне рәхмәт әйтеп киеп куялар. Хәзер инде ашау җитәрлек икән. Туган яктан ни генә килми бит. Сабыйлар йомшак уенчыкларга кадәр җибәрә. Солдат абыйлары аларны йә мылтыгына тагып, йә күкрәк кесәсендә саклап йөртәләр икән. Монда кадере булмаган, анда тансыкка әйләнгән тәм-томнарны җыелышып ашыйлар. Әле күптән түгел Арсланның үзе эшләгән мәктәбе укучылары исемле посылка җибәргәннәр. Матур теләкләр белән хат язганнар. Шуларны күз яшьләрсез укый алмаган ул.

– Үз көнебезне үзебез күрергә өйрәндек инде. Егетләр шулкадәр якын. Бер гаилә кебек яшибез. Бергә кочаклашып йоклыйбыз. Анда күңелгә авыр. Үлем янәшә генә йөри бит. Кайчак дус егетләрнең күңеле төшә. Стресс кичерүчеләр дә бар. Әмма без бер-беребезне ташламыйбыз. Җылы сүзебезне әйтеп, юатабыз, – ди Арслан. – Бар нәрсәнең кадере арты. Сусыз да яшәдек. Ризык булмаган көннәр дә булды. Тормышта гади генә күренгән әйберләрнең никадәр кадерле икәнен аңладык. Монда чиста караватта, йомшак мендәрдә йокласак, тегендә салкын, юеш җирдә дә төн чыгарга туры килә. Ни генә булса да, бер дә начар уйлыйсы килми. Әмма сугыш кырында төрле хәлләр булырга мөмкин. Баламны да үзем үстерәсем килә. Кайткан көнне кулымнан төшмәде улым. Бергә йокладык. Җибәрмичә, кочаклап кына торды. Әти-әнине дә кайгыга саласым килми. Ничә яшьтә булсам да, мин бит аларга бала әле. Хатынымны да бик яратам. Элек төрле чаклар булса да, аерылышып тору безне тагын да якынайтты. Повестка алганнан соң без бер-беребезгә карата үзгәрдек. Матур гына итеп сөйләшәбез, иң җылы сүзләр белән язышабыз.

Арслан, авыр чакта дога коткара, ди. Ул аларны элек тә укыган. Анда баргач, күбрәк искә төшерә башлаган. Ял биргәннәренә рәхмәтле ул. Баштарак, кайтасын белмәгәндә, вакыт узганын сизмәгән дә. Ялга җибәрәчәкләрен белгәч, көнен җиткерә алмыйча тилмергән. Урын алыштыру, уйларны үзгәртү, якын кешеләрне күреп килү кирәк иде, ди.

– Анда егетләр көтә. Бергә булганда көчле без. Бер савыттан, бер телем ипине бүлеп ашаган егетләр бит. Алар миңа бик якын, – ди ул. – Мин элек ике эштә эшләдем. Аллаһы Тәгаләдән, акчалы, бер генә эшем булсын иде, дип тели идем. Теләгем кабул булды. Акчасын да түлиләр. Бер генә эш. Шуларны уйлыйм да, теләкне тели белергә кирәк икән, дим. Хәзер инде уйда бары бер генә теләк: исән-имин, җиңү белән кайтсак идек! Иң җылы, иң рәхәт җир туган якта гына!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җирле үзидарәне булдыруга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Липужина** Валентина Николаевна **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Әлмәт шәһәреннән биш бала анасы **Галимова** Анастасия Юрьевна Татарстан Республикасының **«Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

«Бизнеска нәтиҗәле ярдәм күрсәтү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте әйдәүче икътисадчысы **Вәлиева** Анастасия Александровна, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Ишниязов** Марат Рашат улы, «Автодор» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры **Шәяхмәтова** Рәмзия Вәлиәхмәт кызы **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

1 апрель белән!

1 апрельнең көлке көне икәнен хәзер бөтен кеше дә яхшы белә инде. Без кечкенәрәк чакта бу билгеләмә ул кадәр үк популяр түгел иде. Һәрхәлдә, без аны «алдау көне» дип йөртә һәм бер-беребезне әллә ничекләр итеп алдарга тырыша торган идек. Шугракларыбыз тыңдәшләрен төп башына утырту белән генә чикләнмичә, укытучыларны да кызык итә. Мин үзебезнең сыйныф җитәкчесен ике ел рәттән: «Сезне директор чакыра», – дип кабул итү бүлмәсенә кертеп җибәрдем. Яшь, чибәр кыз иде ул, шуңа алдыйсы килеп кенә тора иде. Ә директор – өлкән яшьтәге бик абруйлы, таләпчән кеше. Ул чакырганда керми калып та булмый. Өченче елда да алдарга иде исәп, тик килеп чыкмады, класс җитәкчебезне директор чынлап та чакырды. Ә укытучы апа алдагы елларны искә төшерептер инде, елмаеп кул гына селтәде. Шуннан дәрес башлангач, директор үзе килеп керде: «Сезгә минем чакыруны җиткерделәрме? Ник кермәдегез? Әйдәгез әле».

Сәхнәдә «конферансье» дип аталган адәм көлдерүче булып эшләгән елларда, бу көн миңа чын мәгънәсендә Көлке көне булып тоела иде. Һөнәри бәйрәм шикелле. Юмор өлкәсендә эшләүчеләр хәтта бер-беребезне котлый да торган идек. Шул рәвешле яши торгач, аның Алдау көне икәне дә, Ахмаклар көне икәне дә онытыла төште һәм мин бер елны күңелем йомшарып китеп, уен-көлке яраткан кайбер агай-энене 1 апрель белән котлап открыткалар җибәрдем. Рәхмәт әйтүче табылмады. Барысы да диярлек үпкәләгән булып чыкты. «Ник ул мине Ахмаклар көне белән котлый?» «Алдакчылар көне белән…» Кеше күңелен күрәм дисәң, адәм көлкесенә калу да, ахмакка әйләнү дә ерак йөрми икән.

Гомумән, юмор ул үзеңне аңлаган кешеләр өчен генә кызык. Аңламый торганнар белән шаярырга маташсаң, үзең дә кызганыч хәлдә калырга мөмкинсең.

Бер ир сөйли, имеш:

– Командировкада чак иде. Беренче апрельдә хатын шалтыратты да: «Мин синнән аерылам, үз бәхетемне таптым, ә син үз тормышыңны үзең җайла. Фатир ачкычы шунда-шунда», – диде. Шуннан ике көн узгач, кабат шалтырата: «Мин шаярттым гына. 1 апрель иде бит», – ди. Ә мин инде подъездга кереп барам. Икенче хатын белән.

Уйнап шаяртсаң да, уйлап эшләргә кирәктер инде. Ә менә бер танышым бөтенләй икенче төрле шаяруга эләккән. Кибет яныннан узып барганда, чибәр генә бер ханым кечкенә баласын тотып торырга куша. Теге танышым сабыйны кулына алып, уси-пуси китерә башлауга, ханым сөрән сала:

– Абый, җиңги, килегез әле! Менә Рөстәмнең әтисе табылды. Үзенең улын күрергә килгән.

Таныш егетем нишләргә белми. Ташлап китеп тә булмый бит инде, кешеләрдән дә оят. Егет кеше ич.

– Нишлисез сез? Нәрсә сөйлисез? – ди җир убылса, кереп качардай хәлгә җитеп. – Мин сезне бөтенләй белмим ич!

– 1 апрель белән, – дип елмая теге гүзәл. Ул кыз әле кияүгә дә чыкмаган икән, сабый абыйсыныкы. Шулай танышып китәләр. Хәзер ун елдан артык яшиләр инде тату гаилә булып. Үзләренең бәләкәчләре дә бар. 1 апрельне ел да бәйрәм итәләр. Шаяралар. Һәм уңышлы шаяралар – барлык балаларының да туган көне 1 гыйнварда.

Менә без, Яңа ел җитә, дип пыр тузабыз бит инде, табын корабыз, бәйрәм итәбез, теләкләр телибез, хыялланабыз. Кем белә инде, бәлки, Яңа ел үзе дә 1 апрель шаяруы гынадыр…

Шулай да 1 апрель элек күңеллерәк була торган иде. Теләсә кайсы темага шаяртып була, кешеләр дә юморны аңлый, юкка-барга үпкәләмиләр, котырып китмиләр иде. Хәзер аз гына бүтәнчәрәк. Мин моның сәбәпләрен төгәл белмим инде. Бәлки, аралашу азаюдандыр. Ни генә әйтсәң дә, уен-көлке ул күмәк кешене ярата. Берүзең генә шаярып булмый. Заманыбыз да тынгысыз. Өсте бөтен, тамагы тук булса да, кеше ут йотып яши. Кайчагында ул үзенең нәрсә өчен борчылуын, ни өчен кайгыруын да аңлый алмый. Шундый халәттәгеләрне елмайту авыр, шаяртуың эч пошыргыч булып тоелырга, нәфрәтләндерергә мөмкин. Алдауның да дәрәҗәсе төште. Көн саен, сәгать саен алданып яшәгән кешедә ниндидер иммунитет сыман нәрсә барлыкка килә, ахры. Аны берничек тә алдап сөендереп булмый. Һәр ялганың җәйнең чираттагы черкие шикелле табигый тоела.

Элек кешене алдау да, үзең алдану да рәхәтрәк иде. Ниндидер язмаларны укыйсың да, гаҗәпләнүдән чәчләрең үрә тора. «Кит аннан! Карале, шулай да була икән бит!» – дип аптырыйсың. Ә ул 1 апрель шаяруы булып чыга. Көләсең рәхәтләнеп. Хәзер аз гына башкачарак. Хәзер рәсми хәбәрләрне укыганда да: «Юктыр ла, мондый мәгънәсезлек тормышта була алмыйдыр. 1 апрель шаяруы гынадыр», – дип уйларга тырышасың. Шуңа ышанасың. Ә ул чынбарлык булып чыга. Көләсе килми.

Ахмаклыкның да абруе юк. Бер чит ил басмасы мондыйрак мәгълүмат бирә: дөньядагы кешеләрнең туксан проценты надан, уйлау-анализлау, үзаллы фикер йөртү сәләтеннән мәхрүм, ди. Ахмак дигән сүз бит инде бу. Дәүләтләр, димәк, дөнья белән әнә шул ахмаклар сайлап куйган ил башлыклары, депутатлар, конгрессменнар һәм башкалар идарә итә дигән сүз. Бу мәгълүматка да ышанасы килми, аны кемнеңдер шаяртуы гына дип уйлыйсы килә. Ләкин…

Тагын бер нәрсә бар әле… Әгәр бөтен адәми затның бары тик икесен генә акыллы дип исбатласалар, дөньядагы һәрбер кеше, кемнең кем булуына карамастан: «Икенчесе кем икән?» – дип баш ватачак.

Менә шулай булгач, тормышка артык җитди карарга кирәкмидер дә инде ул. Шаяртырга кирәктер. Елмаерга, көләргә. Алдарга, алданырга. Ходай биргән ахмаклыгыңның кадерен белеп яшәргә.

Ахмакларым, аңларга тырышыгыз, акыллылар, гафу итегез – барыгызны да 1 апрель белән!

Елмаешып яшик…

1 апрель – Халыкара кошлар көне

ЯЗ КУНАГЫ

Без бала чакта кош оя кормаган урын юк иде бугай ул. Өй кыегында күгәрченнәр гөлдер-гөлдер килә, каралтыкура тирәләрен чыпчыклар сарып алган, абзардагы җепсәләрдә карлыгачлар урнашкан. Бакчага чыксаң, куак-куралар арасында сандугачлар сайрый. Ә су буендагы карт өянкеләрдә каргалар мәш килә…

vk.com

Әмма, нишләптер, күңелгә иртә язда килгән сыерчыклар якынрак кебек. Нилектән шулай икән бу? Язның беренче хәбәрчеләре булгангамы, әллә инде шулкадәр сагындырып та, балаларын очыртырга өйрәтүгә, урманга китеп югалгангамы? Бәлки, күз уңында йөргәнгәдер? Ахыр чиктә безнең йортыбызга кунак булып килә бит инде сыерчык: ишегалдында чемченә, терлек-туар янында мәш килә.

…Шәһәр кырыенда булачак йортыбыз төзелеп кенә ята иде әле. Сыерчык оясы турында сүз кузгаткач, ирем кул гына селтәде. Кырык эш кырык җирдә җәелеп ятканда, янәсе… Кызымның колагына кереп калган. Белоруссиягә машина белән сәяхәткә киткән җирдән оя алып кайттылар. Бик тантаналы төстә гараж кыегына кадаклап куйдык без моны. Урыны да уңайлы кебек. Кояш та төштән соң гына карый, җил дә тими. Менә берзаман сыерчыклар күренә башлады. Сулыш та алмый күзәтәм. Ояны үз итәрләрме икән дигән уй гел бораулап тора бит инде. Йорт каршындагы чыбыкка тезелешеп, чут-чут сайрыйлар. Карап-карап киткәлиләр, әмма сайланалар әле. Нәрсәседер ошап бетми кебек. Кызыма, шаярту катыш, ояның туган җирдә үскән агачтан түгеллеген сизәләр, ахры, дигән сүзләр әйткәлим. Һәм… көннәрдән беркөнне, ниһаять, килделәр. Сөенечнең иге-чиге булмады. Шул көннән сыерчыклар безне ташламадылар. Иртә язда кайталар да, балаларын очарга өйрәткәч, урманга китеп баралар. Ара-тирә, безнең өй исәнме икән дип, күрәсең, сугылып та китәләр үзләре. Ә менә көз җиткәч, җылы якка китәр алдыннан, саубуллашырга кайталар. Нәкъ иртә яздагы кебек өздереп сайрыйлар. Шулайдыр инде, үзәкләре өзеләдер. Нәрсә дисәң дә, туган йорт белән хушлашалар бит. Җырларсың да, еларсың да.

Ә моннан өч ел элек фаҗига булды. Мин сыерчыкның елавына, сыкравына шаһит булдым. Ул барыбызны да әнә шул тавышы белән җәлеп итте дә инде. Күзәтәм шулай: ояга да кергәли, әмма тиз генә атылып чыга, гараж түбәсенә баса да, гүя нидер «сөйли», аңлатырга тырыша. Күңелем сизә: нәрсәдер булган. Баскыч куйдык та ояны аска төшердек. «Идән»ен ачып карасак… әти кош үлеп ята. Туган җиргә кайтам дип, шулкадәр авыр юллар үткәч бит. Йортына кайтып җиткәч. Барыбызның да күзләренә яшь тыгылды. Кадерләп җирләдек. Ә әни кош оя яныннан тәки китмәде. Хәер, китәрлек җире дә булмаган аның. Баксаң, белгечләр әйтүенчә, оя юнәтү – ата сыерчыкларның эше, ана кош алар янына кунакка гына килә икән. Гел шунда моңсуланып, «сөйләнеп» утырды ул. Иң ерак киткән урыны да гараж янында үскән слива агачы булды бугай. Ике атналап вакыт үттеме-юкмы, оя янына пар сыерчык килеп кунаклады. Болары соңга калып кына оя эзләп йөрүчеләр булды, ахры. Инде хәзер куып җибәрерләр дип уйлаган идек. Бик кызгандык үзен. Ни гаҗәп, ятим калган кошны какмады алар. Ялгыз калган сыерчыгыбыз шактый гына вакыт слива агачыннан күзәтеп утырды да, бераздан, дуслашып китеп, бергәләп, көн күрә башладылар. Узган ел тагын шул ук хәл кабатланды: өчәү килеп төштеләр. Быел да шулай. Аптырашып, заманалар үзгәреп тора, кошларның да үзгәрмичә хәлләре юк, дип көлештек. Юкка гына баш ватканбыз. «Ни икән бу?» – дип интернетта эзләнеп карасам, орнитологлар, табигатьтә ата сыерчыкның, гарем оештырып, берничә ана кош белән яшәве булгалый, дип язганнар. Әмма безнеке барыбер гади очрак кына түгел инде. Кошлар авыр чакта үз ишен читкә тибәрмәделәр, хәсрәт утында яндырмадылар, өеннән куып чыгармадылар, йортсыз-җирсез дә калдырмадылар. Менә бит хикмәт нәрсәдә. Без инде хәзер кошларыбызга гаҗәпләнеп түгел, сокланып карыйбыз. Тагын бер сыерчык оясы куярга килештек әле. Балаларына булыр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, республика территориясендә кошларның **321** төре яши. Шуларның **68**е Россия һәм Татарстан Кызыл китабына кертелгән.

Сыерчыкның гәүдә озынлыгы – **20**, койрыгы – **6** см. Авырлыгы – якынча **75** грамм. Төрле тавышлар чыгарып сайрый алалар. Кышлар өчен Европаның көньягына, Африкага һәм Һиндстанга китәләр. Бу кошлар туган җирләренә кайткач, яз үз хокукларына керде дип санала. Әле кайбер җирләрдә кар ятса да, табигать уяна башлый. Күзәтүләр күрсәткәнчә, сыерчыклар **12** ел тирәсе яши. Әмма шушы вакыт эчендә алар берничә буын нәсел калдырырга өлгерә.

Моңсу хатирә

Гомерлек яра

Мин үзем Көлке көнен өнәп бетермим. Күбебез көлдерә белмибез, ниндидер чикне үтеп китәбез кебек тоела. Алдакчылар шулкадәр тырышып җибәрә ки, кайчагында сөенә-сөенә көләсе урынга, йөрәк әрни башлый. Шундый бер очрак бигрәк тә күңелгә кереп калган.

Педучилищеда укып йөргән чак иде бу. 1 апрель көне. Гөлфиянең (исеме үзгәртелде) тәнәфестә, күз яшьләренә тыгылып, атыла-бәрелә йөгереп киткәнен күреп калучылар булган. Әмма кая икәнен беркем белми булып чыкты. Ул вакытта дәресләр калдыру гайре табигый хәл булганга, укытучыларга да барып ирешә бу хәбәр. Ничек һәм кайдан эзләгәннәрдер, анысын белеп бетермим. Тулай торакка кич кенә кайтып кергән Гөлфия. Безнең төркемнән түгел иде ул, әллә ни аралашмадык та. Бәлки, мин бу хәлне шулай онытып та җибәргән булыр идем. Беркөнне шулай кич белән музыка дәресләреннән кайтып барганда, педучилищедан бергә чыктык. Кинәт кенә шул вакыйга искә төште дә, ул вакытта берәр нәрсә булдымы әллә, дип сорап куйдым. Юк, диде ул кыенсынып кына, әмма күз яшьләрен тыя алмыйча елап җибәрде. Аннан бер сулыштан сөйләп ташлады.

– Коридордан барам шулай. Арттан килүче берәү (ул исемен дә атады) миңа: «Гөлфия, сиңа телеграмма килгән», – дип кычкырды. Сораулы күзләрем белән борылып карагач, шундый җитди кыяфәт белән: «Үлем-җитем бугай», – дип тә өстәп куйды. Әнием ул вакытта ялгыз яши иде. Ул мине олыгаеп кына тапкан. Бик укытасы, кеше итәсе килде инде. Башкалардан ким булмасын дип тырышты. Ял көннәрен бергә үткәргән идек. «Кызым, авыраеп торам әле», – дип, капка төбенә озатырга чыккач, бик моңсуланып калды. Югыйсә һич югында беренче каттагы хатлар куела торган урынга төшеп карарга бит инде миңа, телеграмманы кулыма тоттырырга тиешлекләрен дә чамаларга иде. Әни, дигән уй минем бөтен гәүдәмне бөтереп алды, күрәсең. Сәгатемә карасам, 35 минуттан электричка китә. Өлгерәм дигән уй белән башымны алып чыгып йөгергәнмен. Өлгердем. Ерак түгел безгә, кырык минутлап кына барасы, станциягә төшкәч, унбиш минутлык юл. Поезддан берничә авылдаш та төште. Әни турында ләм-мим. Ишетмәгәннәрдер инде, дип уйлыйм. Алар да кайдандыр кайтып киләләр бит. Тиз-тиз авылга төштем дә, урамга кергәч, йөгерергә үк тотындым. Инде йортыбыз да күренә. Тынлык. Капка да ябык. Кеше дә күренми. Ишегалдына килеп керсәм, әни терлек-туар карап йөри. Исән-сау. Мине дә елмаеп каршы алды. Тик шунда ук җитдиләнде. Әле киткәнемә бер генә көн бит. Вакытлы-вакытсыз нишләп йөрим, янәсе. «Практика көне, әни, дәресләр бирмәгәч, беркая да барасы булмады. Хәлеңне белеп килим», – дип мыгырдандым. Рәхәтләнеп чәй эчтек тә, кичке якта китеп бардым. Шушы вакыт эчендә ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. Соңыннан 1 апрель икәнлеге искә төште инде, әмма нәрсәдән көләргә икәнлеген генә аңламадым. Бу хәл гомергә дә онытылмас инде.

Укуны тәмамлагач, Гөлфия белән аралашканым булмады. Әмма һәр 1 апрельдә күз алдыма шушы күренеш күз алдына килеп баса. Менә ул педучилище коридорында басып тора, автобус тукталышына төшә, электричкага утыра, йөгерә-атлый өйләренә кайтып җитә… Күпме вакыт чарасызлыктан йөрәге әрнегән бит кыз баланың. Һәм гомерлеккә яра булып калгандыр, мөгаен.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яшьләр дөньясы

«БУ БОЗНЫ СТУДЕНТ ВАТТЫ»

Әмма бу горурлану өчен бердәнбер сәбәп түгел. Хәтерегездәме, 6 декабрьдә Универсиада авылы тулай торагы янын боздан чистарткан егет турында күпме яңалык чыкты. Даниил Каргинов ул. Егет үзе яшәгән тулай торак коймасына: «Бу бозны студент ватты (төнге 1.30 сәгатьтән иртәнге 6.30га кадәр). Ул, моның өчен җаваплы кешеләрдән аермалы буларак, көн саен биредән үтеп йөрүчеләрнең тормышы һәм саулыгына битараф түгел!» – дип, язу да элеп калдыра.

Шушы көннәрдә Даниил «СТС» каналында бара торган «Суперниндзя» тамашасының финалисты булды. Популяр шоу катнашучысы белән без дә әңгәмә кордык.

:: Даниил, үзең белән якыннанрак таныштыр әле.

– Мин Азәрбайҗан башкаласы кояшлы Бакуда туып-үстем. Анда татар бәйрәмнәрендә ярышлар оештыра идем. Кыскасы, татар мәдәнияте һәм традицияләре миңа якын иде. Шуңа күрә Казан федераль университетына укырга кердем. Хәзер инде мин, дүртенче курсны тәмамлап, диплом якларга әзерләнәм. Спорт белән дуслык бәләкәй чактан ук башланды. Сигез яшьтән дзюдога йөрдем, аннары воркаут (урам тренировкалары. Күнегүләр күбесенчә турник һәм шуларга охшаш урам конструкцияләрендә ясала. – **Авт.**) һәм җиңел атлетика белән мавыктым. Шулай итеп, 2017 елга кадәр спорт белән һәвәскәр буларак шөгыльләндем. Беркөнне абыем миңа «Русский ниндзя» һәм «Гонка героев» тапшыруларының чыгарылышларын күрсәтте. Кызыгып киттем, спорт белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнү максаты барлыкка килде! Шушы максатыма быел ирешергә язган булган икән. Тамашада катнашып, аның финалисты булдым!

:: Трассадагы сынауларны нинди шартларда узарга туры килде?

– Кыенлык буенча ярышлар дәрәҗәсен бәяләү мөмкин түгел диярлек! Кызганыч, һава шартлары начар иде: яңгыр яуганга күрә, трасса юеш һәм тайгак булды. Әйтергә кирәк, бәхет эше бу, сиңа ничек язган бит. Дөресен әйтим, «Кастингны уздың», – дип шалтыраткач, «Суперниндзя» тамашасына ныклап әзерләнергә вакыт та калмады. Әмма сәламәт яшәү рәвеше алып барганга күрә, махсус әзерлексез дә яхшы формада идем.

:: Әлбәттә! Шулкадәр спорт белән дус булып, 84 чакрым йөгереп, парашют белән сикереп, төрле узышларда катнашып…

– Бер сүз белән әйтсәк, бу – функциональ үсеш. Мин дөрес туклану, йокы һәм күнегүләр режимын сакларга тырышам. Әйтик, көн саен кимендә 8 сәгать йоклыйм. Әмма командировкалар аркасында, бу һәрвакытта да мөмкин түгел. Универсиада авылы тулай торагы янындагы бозны да төн буе ватарга туры килде. Шундый очракларда мин төшке аш вакытында 1–1,5 сәгать йоклыйм. Тренировкаларга атнасына кимендә 6 тапкыр йөрим. Мәсәлән, иртәнге ашка кадәр түбән пульста йөгерәм, аннары гомуми физик күнегүләр һәм тартылу. Кичкә таба функциональ тренировка һәм махсус җиһазлар (каршылыклар) кулланып, трасса узам. Мин гадәттә саф һавада, хәтта 30 градус салкында да күнегүләр ясауны өстен күрәм.

:: Тормышта спорттан башка тагын нәрсә белән мавыгасың?

– Нәсел шәҗәрәсен төзеп, аның турында китап язам, физик культура турында фәнни материалларны өйрәнәм. Шулай ук бисер һәм Каспий кыслаларыннан эшләнмәләр ясыйм, роликта йөрим һәм даими рәвештә үземне яңа өлкәләрдә сынап карыйм.

:: Нәсел шәҗәрәсе дигәндә, «Суперниндзя» тамашасында сине Тифлис кенәзенең варисы дип таныштырдылар.

– Өебездә нәсел тарихына бәйле бик күп документлар сакланган. Шуңа күрә миңа яшь вакытта ук шәҗәрә агачын өйрәнү кызык иде. Хәзер мин 11 буынга кадәр нәселне беләм, әмма һаман да аны өйрәнүне дәвам итерәм. Сүз уңаеннан, бабамның бабасы Тифлис шәһәрендә кенәз булган. Ә әбиемнең әбисе Елизавета патша армиясе офицеры, хәрби табиб Каргинов Аслан Дзамбулат улына кияүгә чыккан. Рус-япон сугышыннан соң Баку шәһәрендә холера эпидемиясе башланган. Шунда табиблар төркеме белән бабамның бабасын да җибәргәннәр. Бәхеткә, алар эпидемияне җиңә алган һәм ул Бакуда калырга булган. Шулай итеп, безнең яңа тарих башлана. Ул үз вакытында туганнарым һәм әнием бүген яши торган йортта яшәгән.

:: Киләчәккә планнарың хакында берничә сүз дә әйтсәң иде.

– Диплом якларга, магистратурага керергә һәм «Суперниндзя» тамашасының финалында җиңеп, яңа сезонга эләгергә! Шулай ук 2028 елда каршылыклар булган узышлар буенча Олимпия Уеннарында катнашырга ниятлим. Мин шундый узышлар буенча Европа чемпионатында катнашуга квалификация алдым, шуңа хәзер анда да чыгыш ясарга әзерләнәм.

Диана КАРПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 246

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+